# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

## КАРАРЫ

2020 ел. 9 гыйнвар №269

**2020 елга Апас муниципаль районының муниципаль берәмлекләренең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фаразлау планын(программасын) раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» гы Федераль законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2007 елның 5нче декабрендә, 198 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмә һәм Апас муниципаль районы Уставы нигезендә, Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1. 2020 елга Апас муниципаль районының муниципаль берәмлекләренең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фаразлау планын(программасын) раслау турында расларга**.**

2.Әлеге карар район «Йолдыз» («Звезда») газетасында басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Апас муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесе Рәисенә йөкләргә.

**Апас муниципаль районы Башлыгы -**
**Апас муниципаль район Советы Рәисе Р.Ф. Хисамутдинов**

2020 елга Апас муниципаль районының муниципаль берәмлекләренең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фаразлау планы (программасы)

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Апас муниципаль районы муниципаль берәмлекләрен муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның 2020 елга фаразлау планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» гы Федераль законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 5.09.2007 елдагы № 198 карары белән расланган Апас муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмә һәм Апас муниципаль районының Уставы нигезендә эшләнде.

## 2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2.1. 2020 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль күчемсез мөлкәт (1 нче таблица).

2.2. 2020 елда хосусыйлаштырырга тиешле муниципаль күчмә мөлкәт(2 нче таблица).

1 нче таблица

2020нче елда ачык аукционнарда
тәкъдимнәр кертү юлы белән сатылычак күчемсез дәүләт мөлкәтенең исемлеге

| № п/п | Объектның адресы | Объектның исеме | Мәйданы (кв. м) | Планлаштырылган сату вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | ТР, Апас районы, Сатмыш авылы, Үзәк ур., 42 йорт | Торак булмаган бина (ашханә) һәм җир кишәрлеге | 306,7 | 2020 елның 1-2 кварталы |
| 2 | ТР, Апас районы, Идрәс-Тинки авылы, Пушкин ур., 18 йорт | Торак булмаган бина (ашханә) | 95,4 | 2020 елның 1-2 кварталы |

2 нче таблица

2020 елда ачык аукционнарда сатылырга тиешле күчмә мөлкәт исемлеге

| № п/п | Объектның адресы | Объектның исеме | Планлаштырылган сату вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | ТР, Апас районы, Апас ш.т. п., Совет ур., 2 йорт | LADA, 212140 LADA 4x4 | 2020 елның 1-2 кварталы |